


1 сентябрьгә санаулы кон калып бара. Әти-әниләр, укучылар жин сызганып яна уку елына әзерләнә: мәктәп кирәк-яраклары, уку киемнәре ала. Ә мәктәпләр укучыларны кабул итәргә әзерме сон?
22 августта бу мәсьәләне ачыклаган чираттагы Мордовия Республикасы Правительствосы утырышы vтте. Мәгариф министры Евгений Маркачев мәгариф учрежденияләренен яна уку елына әзерлеге турында бәян итте. Әйтеп китик, Мордовия Главасы kvп тапкыр мәктәпләрне яна уку елына вакытлы һәм сыйфатлы әзерләvнен кыйммәте турында әйткән иде чыгышларында.
Саннарга игътибар итик. 2016-2017 уку елында Мордовиядә 253 балалар бакчасы, 352 мәктәп, 11 интернат, 23 урта профессиональ һәм 54 - балаларга остәмә белем бирv (барлыгы 693) учреждениеләр эшләр. Мәктәпләрдә 69 366 укучы, аларнын 7 437 беренче тапкыр барыр; 4 158 класс - комплект эшләр. Саннар vткән елдагы кебек.     Унышлы мәктәпләрне ремонтлау һәм реконструкцияләv программасы vтәлде. Kvп белем йортынын котельнялары алыштырылды, фасадлары янартылды, спортзаллары ремонтланды, ишек-тәрәзәләр куелды, мебель сатып алынды, ашханәләр тәртиптә, яна жиһазлар (интерактив такталар) да булдырылды. Игътибар vзәгендә булган янгынга, террорчылыкка каршы чаралар vткәрелде, мәктәпләрдә тиешле санитар-эпидемиология иминлек булдырылды, дип хәбәр итте министр.
Китапларга кагылышлы; бvгенге кондә федераль һәм региональ исемлектәге дәреслекләрне сатып алу очен, мәктәпләр ихтыяжларын исәптә тотып, 62014,2 мен сум бирелгән. Уку елы башланганчы барлык акча vзләштерелгән булыр, дип ышандырды Евгений Маркачев.
Правительство әгъзалары белән Мордовия мәгариф министрлыгы эшенә унай бәя бирелде.
Аерым тема буларак мәктәп автобуслары иде.
- Теньгушево районында оч автобус маршруты буендагы юллар таләпләргә жавап

кайтармыйлар, - дип билгеләде Мордовия Правительствосы Председателе Владимир Сушков, - Якын арада аларны нормалар буенча эшләргә кирәк.
Шулай ук  мәктәплләрдә электрон картадан 100% куллану таләп ителә – карта ярдәме белән мәктәпкә керергә, ашаган очен (ашамлыкларны сайлап ашау каралган булырга тиеш) тvләргә, жәмгыять транспортында (аерым очракларда) тvләп йорергә. Утырышта шундый һәм башка сораулар да чишелде.
Татар мәктәпләренә килгәндә, Яна уку елын каршы алырга әзерләр. Темник районы Тархан гомуми урта белем бирv мәктәбендә унбиш ел тырышып директор булып хезмәт иткән Халисә Сафиулла кызы Кугушева белән аралаштым. Ул: “Быел мәктәпнен беренче сыйныфына Тархан белән Ишейки авылларыннан оч укучы – Кариева Камила, Новокрещенова Оля, Ескин Артем (беренче укытучылары - олы педагогик стажлы, хормәтле Адилә Кәрим кызы Дулатова) киләләр, ә 11нче сыйныфны 2 укучы тәмамлады. Барлыгы 22 укучыбызга белем һәм тәрбия бирергә әзербез.
Яна уку елына мәктәп әзер дип әйтә алам. Тикшерvләр vтте, китаплар житәрлек, хокvмәт белән бирелгән акчага мәктәп бинасына косметик ремон ясалды, яз башы утырткан голләр чәчәк атып утыралар. Әмма бер проб-лемабыз тынгылык бирми – Тархан урта мәктәбебезнен тәрәзә рамнары черегән. Выпускникларыбыз, яки башка мәрхәмәтле спонсорлар табылса иде бу эшкә. Иганәчелек (благотворительность) – хәйрияле эш гомер гомергә хормәткә лаек.
Форсаттан файдаланып, Мордовия укытучыларын, vземнен барлык  коллегаларымны һәм укучыларны, аларнын әти-әниләрен 1 сентябрь – Белем коне белән ихлас котлыйм. Унышлы уку елы, саләмәтлек, яна казанышларга һәм ачышларга омтылышлар, ботен башлангычларда ижадилык һәм унышлар телим», - ди Халиса Сафиулла кызы.

**Н.Хәлил**